КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 август г.Казань № 944

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 324 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 324 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 30 май, 443 нче; 2012 ел, 25 июль, 630 нчы; 2012 ел, 6 ноябрь, 969 нчы; 2013 ел, 7 март, 154 нче; 2014 ел, 16 май, 326 нчы; 2014 ел, 11 август, 580 нче; 2015 ел, 28 май, 386 нчы; 2016 ел, 26 февраль, 120 нче; 2016 ел, 19 сентябрь, 656 нчы; 2017 ел, 8 июнь, 361 нче; 2017 ел, 11 декабрь, 972 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1114 нче; 2018 ел, 27 сентябрь, 865 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1144 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1190 нчы; 2019 ел, 23 май, 433 нче; 2020 ел, 4 февраль, 74 нче; 2020 ел, 14 февраль, 109 нчы, 2020 ел, 12 ноябрь, 1016 нчы, 2021 ел, 28 гыйнвар, 34 нче, 2021 ел, 13 август, 711 нче, 2022 ел, 1 июль, 616 нчы, 2022 ел, 29 июль, 732 нче, 2022 ел, 30 декабрь, 1472 нче, 2023 ел, 24 март, 332 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары системасы һәм структурасы турында» 2023 елның 4 маендагы 276 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

2 һәм 3 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. 2023 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы аппараты хезмәткәрләренең иң чик санын, вазыйфаи окладлары буенча хезмәт өчен түләүнең айлык фонды 3 451,093 мең сум булган 137 берәмлек күләмендә билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына министрның алты урынбасарының, шул исәптән министрның беренче урынбасарының да, булуын рөхсәт итәргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органы» сүзләренә, «республика максатчан программалары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программалары» сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктта «предприятиеләр, учреждениеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктта:

2.1.1 пунктчада «территориаль үсеш схемасы» сүзләрен «территориаль планлаштыру схемасы» сүзләренә алмаштырырга;

2.1.2 пунктчада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә, «Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2.1.7 пунктчада «территориаль үсеш схемасы» сүзләрен «территориаль планлаштыру схемасы» сүзләренә алмаштырырга;

2.1.9 пунктчада «үсеш буенча озак сроклы һәм урта сроклы программалар» сүзләрен «үсеш стратегияләре» сүзләренә алмаштырырга;

«*» астөшермәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«* Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары эшчәнлеген оештыру турында» 2023 ел, 26 июнь, 752 нче карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт идарәсе функцияләре кодификаторы буенча.»;

4.1 пунктта:

4.1.2 пунктчаның икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.6 пунктчада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органнары» сүзләренә, «республика максатчан программалары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт программалары» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.7. Сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләре хезмәткәрләренә һөнәри белем алуга, өстәмә һөнәри белем алуга, шулай ук Татарстан Республикасы

территориясендә эшчәнлек алып баручы сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләренең кадрлар потенциалын үстерүнең башка юнәлешләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыруда ярдәм итә.»;

4.1.9 һәм 4.1.10 пунктчаларны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4.1.9. Сәнәгать һәм сәүдә өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программалары проектларын эшли һәм республика башкарма хакимияте органнарының, оешмаларның Россия Федерациясе дәүләт программаларын, федераль максатчан программаларны, сәнәгать һәм сәүдә өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру эшчәнлеген координацияли.

4.1.10. Сәнәгать һәм сәүдә өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын гамәлгә ашыру, Татарстан Республикасы икътисадын үстерүнең өстенлекле юнәлешләре мәсьәләләре буенча хөкүмәт карарларын әзерләүдә катнаша.»;

4.1.12 пунктчада «предприятиеләр һәм коммерцияле» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1.16 пунктчада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.20 пунктчада:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы бюджеты» сүзләреннән соң «тиешле елга һәм план чорына» сүзләрен өстәргә;

4.1.25 пунктчада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.26 пунктчада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.28 пунктчада «предприятиеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1.31 пунктчада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.41 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.41. Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләренең югары һәм урта һөнәри белем бирү программалары буенча кадрлар әзерләүдә, эшче һөнәрләре буенча һөнәри әзерлек программалары буенча кадрларны тизләтелгән әзерләүдә, эшчеләрне яңадан әзерләүдә ихтыяҗын ел саен фаразлый.»;

4.1.57 пунктчада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.67 пунктчада «предприятиеләр һәм коммерцияле» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.1.70 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.70. Казан, Түбән Кама, Чаллы, Зәй шәһәрләрендә «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең, «ТГК-16» акционерлык җәмгыятенең, «Түбән Кама җылылык-электр централе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү чыганакларыннан җылылык белән тәэмин итү системалары ышанычлылыгын арттыру чаралары системасын билгели.»;

4.1.77 пунктчада «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.89 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.89. Документларны карый һәм халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларының, Министрлык эшчәнлеге өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган масштаблы инвестиция проектларының, Татарстан Республикасы Җир кодексына кушымтада күрсәтелгән критерийларга туры килүе турында дәлилләнгән бәяләмәләр проектларын, шулай ук мондый объектлар һәм проектлар параметрларына үзгәрешләр кертүнең максатка ярашлы булуы турында дәлилләнгән бәяләмәләр проектларын килештерә;»;

4.1.106 пунктчада «Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 4.1.116 һәм 4.1.117 пунктчалар өстәргә:

«4.1.116. «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941 - 1945 еллар.» республика исемен бирү турында таныклыклар бланкларын әзерләүне, саклауны, Татарстан Республикасы Рәисенә кул кую өчен күрсәтелгән республика исемен бирү турында таныклыклар әзерләүне һәм тапшыруны, шулай ук аны бирү турында бирелгән таныклыкларны исәпкә алуны тәэмин итә.

4.1.117. Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә предприятиеләрендә хезмәтне саклау һәм иминлек техникасы өлкәсендәге проблемалар буенча мәсьәләләрне карап тикшерүдә һәм тәкъдимнәр әзерләүдә катнаша.»;

5.1 пунктта:

5.1.1 пунктчада «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, учреждениеләр, оешмалар, предприятиеләр» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары, оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

5.1.2 пунктчада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

5.1.3 пунктчада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

5.1.8 пунктчада «министрлыклар һәм ведомстволар» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

6.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Премьер-министры тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

6.3 пунктның икенче абзацында «дәүләт хакимияте башкарма органнары, оешмалар һәм предприятиеләр» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары, оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы структурасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

3. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына әлеге карарның 1 пунктының дүртенче – алтынчы, илле бишенче абзацларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүче оештыру карарларын законнар нигезендә кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 04 август, 944 нче карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгы структурасы

